ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 ел 30 март**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 793**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре, Бауман урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында » 2016 елның 14 гыйнварындагы 63 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

ТР Зеленодольск шәһәренең Бауман урамындагы 4 нче йортны авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программадан чыгару белән бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетның «Зеленодольск муниципаль районында авария хәлендәге күпфатирлы йортлар исемлеген раслау турында» 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы Зеленодольск муниципаль районы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 февралендәге 359 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре, Бауман урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында » 2016 елның 14 гыйнварындагы 63 номерлы карарының үз көчен югалтуын таныйрга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы органга;
- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ;
- торак урыннар милекчеләренә.

3.Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматы рәсми порталында һәм Зеленодольск муниципаль районының http://zelenodolsk.tatarstan.ru мәгълүмат сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин